ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ГАЙТӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ ГАЙТАНКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

423014, РТ, Нурлат районы, Гайтән авылы, Үзәк урам 1нче йорт,
Тел. 8 (84345) 3-98-01

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» октябрь 2019 ел № 1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлегенең Гайтән авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гайтән авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы «Гайтән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. Гайтән авыл җирлеге Гайтән авылында Спорт урамы буенча 1-54 нче йорттан, Эшчеләр урамы буенча 1-24 нче йорттан, Күл урамы буенча 1-13 нче йорттан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын 2019 елның 12 ноябрендә 18 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. 2019 елның 17 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Гайтән авылы, Үзәк урам, 13нче йорт янында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гәйтән авыл җирлеге Гәйтән авыл җирлегендә Кыр урамы буенча 1-28, Бакча урамы буенча 1-28 а, Елга аръягы урамы буенча 1-7 нче йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2019 елның 22 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка Гайтән авылы, Үзәк урам, 13нче йорт янында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлегенең Гайтән авылында Үзәк урамы буенча 1-22, Яшьләр урамы буенча 1-39, Тынычлык урамы буенча 1-6, Көнчыгыш урамы

буенча 2-8 нче йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.

4. Гражданнар җыенын уздыру өчен Гайтән авылында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

5. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гайтән авыл җирлегенең Гайтән авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидтан тыш, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:

1) Гайтән авылында су чыганагын норматив таләпләргә китерү буенча эшләр үткәрү.

2) Гайтән авылы зиратын койма белән әйләндереп алу.

«ӘЙЕ» «ЮК».

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Гайтән авыл җирлеге башлыгы Н. В. Авдеева